ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш,
422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы,
422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

23.10.2020 №2-1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге
Канаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004нче елның 28нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме? - «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылында чишмәләрне төзекләндерү»

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә, сайлау хокукына ия булган халык исемлегенә 69 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 43 граждан кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 43 кеше тавыш бирде, «Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип таныырга.

2. «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны юнәлдерүгә килешәсезме: -«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү».

3.Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: С. П. Набаткина